| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25.04.2025 с.Старое Дрожжаное № 131

2024 елның 13 июлендәге 177-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә аерым муниципаль норматив хокукый актларга үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 13 июлендәге 177-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 12 сентябрендәге 366 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы бюджеты керемнәренең баш администраторлары тарафыннан үз карамагындагы бюджет вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибенең **2 пунктындагы «б» пунктчасына** түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**6 абзацта** «тапшыру» сүзеннән соң «түләнергә тиешле сумманы исәпләгән көннән дә соңга калмыйча» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле яңа **жиденче абзац** өстәргә:

«бюджетка түләүләр буенча дебитор бурычларын, пенялар һәм штрафлар буенча Россия Федерациясе Финанс министрлыгы билгеләгән гомуми таләпләр нигезендә эшләнгән вәкаләтләрне гамәлгә ашыру регламентын билгеләү;».

2. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 28 апрелендәге 194 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Башкарма комитетының административ комиссиясе тарафыннан салынган административ штрафларны түләү бурычларын түләтүгә өметсез дип тану һәм исәптән чыгару турында карарлар кабул итү тәртибенең **2.1 пунктына**, аны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә:

«2.1. Билгеләнгән вакытта бюджетка түләнмәгән түләүләр (бюджетка түләүләр буенча бурыч) түләнүгә өметсез дип танылган очракта:

1) бюджетка түләүләр түләүче физик затның үлеме яки аны Россия Федерациясенең Гражданлык процессуаль законнары нигезендә үлгән дип игълан итү;

2) «Бөлгенлек (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә гражданның, индивидуаль эшкуарның банкротлык процедурасын тәмамлау - күрсәтелгән Федераль закон нигезендә азат ителгән бюджетка түләүләр буенча бурыч өлешендә;

3) оешманың милке җитмәү сәбәпле һәм (яки) әлеге оешманы оештыручылар (катнашучылар) тарафыннан Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә түләү мөмкин булмау сәбәпле, бюджетка түләүләр буенча бурычлар буенча түләнмәгән оешманы бетерү;

4) штрафка тартылган яисә суд тарафыннан карар кабул ителгән, аның нигезендә бюджет керемнәре администраторы бюджетка түләүләр буенча бурычларны, шул исәптән аны түләтүнең билгеләнгән срогы чыгуга бәйле рәвештә, түләтү мөмкинлеген югалта торган җәзага карата амнистия яисә кичерү турында актлар куллану;

5) «Башкару эшчәнлеге турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яисә 4 пунктында каралган нигез буенча башкарма документны түләтүчегә кире кайтарып биргәндә, күләме банкротлык турындагы эш буенча производство ачу өчен Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән бурычка карата таләпләр күләменнән артмаган бурыч барлыкка килгән көннән алып биш елдан артык вакыт үтсә, суд приставы-башкаручы тарафыннан башкарма документны кире кайтару;

6) банкротлык турындагы эштә кулланыла торган процедураларны уздыруга суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек акча булмауга бәйле рәвештә банкротлык турындагы эш буенча гаризаны кире кайтару яисә җитештерүне туктату турында суд тарафыннан акт кабул итү;

7) теркәүче орган карары буенча юридик затны юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру һәм «Башкару эшчәнлеге турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы Федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яисә 4 пунктында каралган нигез буенча башкарма документны түләтүчегә кире кайтаруга бәйле рәвештә башкару эшен тәмамлау турында суд приставы-башкаручы тарафыннан элек чыгарылган карарның булуы, - оешманың мөлкәте җитәрлек булмау һәм Россия Федерациясе законнарында каралган очракларда аны гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан түләп бетерү мөмкин булмау сәбәпле бюджетка түләүләр буенча түләнмәгән бурыч өлешендә. Теркәү органының «Юридик затларны һәм индивидуаль эшкуарларны дәүләт теркәвенә алу турында» 2001 елның 8 августындагы 129-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә юридик затны юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру турындагы карары гамәлгә яраксыз дип танылган очракта, элек әлеге пунктча нигезендә түләтүгә өметсез дип танылган бюджетка түләүләр буенча бурыч бюджет (бухгалтерлык) хисабында.».

3. Әлеге карар рәсми басылып чыгарга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.И. Мөхәммәтҗанов